# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Чернышевка ав. торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

02 декабрь, 2020 ел № 3

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “2021 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Чернышевка ав. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:
- Чернышевка авылындагы күпфатирлы йортларны төзекләндерүгә (киртәләү);
- Чернышевка авылы балалар мәйданчыкларын сатып алу һәм төзекләндерү;
- Чернышевка авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыруга;
- Чернышевка авылындагы бистә эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алуга

үтәү буенча юллау белән килешәсезме?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча 2020 елның 25 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2020 елның 02 декабрендә 17 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 827 (сигез йөз егерме җиде) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 447 кеше, бу 52,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 332 (өч йөз утыз ике) катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 115 (йөз унбиш) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка

авыл җирлеге Чернышевка ав. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Чернышевка ав. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) суммада үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- Чернышевка авылындагы күпфатирлы йортларны төзекләндерүгә (киртәләү);
- Чернышевка авылы балалар мәйданчыкларын сатып алу һәм төзекләндерү;
- Чернышевка авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыруга;
- Чернышевка авылындагы бистә эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алуга.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А.К.Җамалиев

Чернышевка авыл җирлеге Башлыгы О.А.Маланин